ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасыннан сайланган сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары эшчәнлеге турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасыннан сайланган сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты А.З. Фәрраховның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы объектларын һәм чараларын федераль программаларга, дәүләт корпорацияләренең инвестиция программаларына, үсеш институтлары һәм федераль фондлар программаларына кертү юлы белән федераль акчалар һәм бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү мәсьәләләре буенча эшче төркемнәр эшчәнлеген нәтиҗәле дип танырга.

3. Россия Федерациясе сенаторлары Г.Е. Емельяновка, А.М. Терентьевка, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары И.Б. Богуславскийга, И.С. Вольфсонга, Р.Г. Гаджиевка, И.И. Гыйльметдиновка, Р.Г. Кәлимуллинга, Ә.Г. Когогинага, Т.П. Ларионовага, А.Р. Метшинга, О.В. Морозовка, М.Г. Нуриевка, А.В. Прокофьевка, М.А. Топилинга, А.З. Фәрраховка, А.Ф. Ягъфәровка, Е.А. Ямпольскаяга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасында билгеләнгән бурычларны гамәлгә ашыруда актив катнашырга.

3.2. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары белән бергәләп Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын кертү һәм алып бару буенча эшләүне дәвам итәргә.

3.3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында үткәрелә торган «хөкүмәт сәгате» кысаларында карау өчен сораулар әзерләү өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләре белән үзара эшчәнлекне көчәйтергә.

3.4. Сайлаучылар наказлары буенча эшләүне, шул исәптән сайлаучылар наказларын, кирәк булган очракта, федераль программаларга кертүне, активлаштырырга.

3.5. Беркетелгән сайлау округларында Татарстан Республикасында үткәрелә торган чараларда катнашу тәҗрибәсен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Россия Федерациясе дәүләт программаларын үтәү кысаларында федераль акчалар җәлеп итү мәсьәләләре буенча җаваплы эшче төркемнәр билгеләргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2390-VI ДС